**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5997**
**13.11.2020**

Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5946 номерлы карары белән расланган балигъ булмаган затны эмансипацияләү (балигъ булмаган затны тулысынча хокукка сәләтле дип белдерү) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 2 октябрендәге 5946 номерлы карары (Башкарма комитетның 2017 елның 3 октябрендәге 5900 номерлы, 2018 елның 14 ноябрендәге 6678 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган балигъ булмаган затны эмансипацияләү (балигъ булмаган затны тулысынча хокукка сәләтле дип белдерү) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, 2.5 пунктның икенче баганасындагы бишенче абзацында «Хезмәт кенәгәсенең (хезмәт шартнамәсенең) күчермәсе» сүзләрен «Хезмәт кенәгәсенең (хезмәт шартнамәсенең) күчермәсе яки тиешле рәвештә кәгазьдә расланган яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (эш бирүчедә булганда) белән имзаланган электрон документ формасында хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов